ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　КАРАР

19.07.2023　　　　№ 728

«Опекун (попечитель) һәм тәрбиягә бала алган гаиләдә баланы тотуга айлык түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 02 мартындагы 238 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 02 мартындагы 238 номерлы карары белән расланган опекун (попечитель) һәм тәрбиягә бала алган гаиләдә баланы тоту өчен айлык түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.6.1 пунктның 1 пунктчасында "Россия Федерациясе Пенсия фонды" сүзләрен «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды» сүзләре белән алыштырырга;

1.2. 2.6.1 пунктның 5 пунктчасында "Россия Федерациясе Пенсия фонды" сүзләрен «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды» сүзләре белән алыштырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге начальнигына йөкләргә.

Җитәкче　　　　Сәйфетдинова З.Р.